ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.07.2017 Казан ш. № 6-65/тп

Тоташтырыла торган җылылык басымының куәт бирәмлегенә хисаплаганда «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру тәртибе турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 16 апрелендәге 307 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынучы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карарга 1 нче кушымтага туры китереп, мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмаучы объектын «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык басымының куәт берәмлеге исәбеннән түләү билгеләргә.

2. Шушы карарга 2 нче кушымтага туры китереп, мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы техник тоташтыру мөмкинлеге булганда сәгатенә 1,5 Гкал артып китүче объектын «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык басымының куәт берәмлеге исәбеннән түләү билгеләргә.

3. Бу карарның 1 нче һәм 2 нче пунктларында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
21.07.2017 № 6-65/тп карарына
1 кушымта

Мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмаучы объектын «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык басымының куәт берәмлеге исәбеннән түләү

мең сум/Гкал/сәг

| № п/п | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 2,525 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең тоташтырыла торган җылылык басымы 0,1 Гкал/сәг артык һәм 1,5 Гкал/сәг артмаучы объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өсте) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | каналлы салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 2 824,842 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | 2 575,455 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең тоташтырыла торган җылылык басымы 0,1 Гкал/сәг артык һәм 1,5 Гкал/сәг артмаучы объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
21.07.2017 № 6-65/тп карарына
2 кушымта

# Мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык басымы техник тоташтыру мөмкинлеге булганда сәгатенә 1,5 Гкал артып китүче объектын «Энерготранзит» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылы белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында, тоташтырыла торган җылылык басымының куәт берәмлеге исәбеннән түләү

мең сум/Гкал/сәг

| № п/п | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 2,525 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык басымы 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өсте) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | каналлы салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 1 940,451 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | каналсыз итеп салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | 1 978,845 |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең техник тоташтыру мөмкинлеге булганда тоташтырыла торган җылылык басымы 1,5 Гкал/сәг артып китүче объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар (П $_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге